РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

30. 11. 2021 Олы Кайбыч ав. № 12

**Республикасы Татарстан Кайбыч муниципаль районы хосусый йорт биләмәләре территорияләрен иң яхшы Яңа ел бизәлешенә конкурс уздыру турында**

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен оештыру һәм үткәрүгә бәйле рәвештә:

1. Республикасы Татарстан Кайбыч муниципаль районы хосусый йорт биләмәләре территорияләрен иң яхшы Яңа ел бизәлешенә конкурс игълан итәргә.
2. Республикасы Татарстан Кайбыч муниципаль районы хосусый йорт биләмәләре территорияләрен иң яхшы Яңа ел бизәлешенә конкурс уздыру турында нигезләмәне расларга (1нче кушымта).
3. Конкурс комиссиясе составын расларга (2нче кушымта).
4. Авыл җирлекләре Башлыкларына конкурста катнашу өчен үз җирлекләрендә яшәүчеләргә мәгълүмат җиткерүне тәкъдим итәргә.
5. Кайбыч муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә район халкын әлеге күрсәтмә белән таныштырырга.
6. Әлеге күрсәтмәне массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
7. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Башлык урынбасары Хәялиев Р.Р.ка йөкләргә.

**А.И.Рәхмәтуллин**

1нче кушымта
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгының 30.12.2021
12 номерлы күрсәтмәсе белән
РАСЛАНГАН

**Хосусый йорт территорияләренең иң яхшы Яңа ел бизәлешенә конкурс уздыру турында**
# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы хосусый йорт территорияләренең иң яхшы Яңа ел бизәлешенә конкурска (алга таба - Конкурс) әзерлек, оештыру һәм уздыруның гомуми тәртибе һәм шартларын билгели.

### Конкурсның максаты

Районның торак пунктларына бәйрәм төсе бирү, әлеге эшкә район халкын җәлеп итү. Яңа ел социаль рекламасы проектларын гамәлгә ашыру һәм биналарны бизәү, Яңа ел бәйрәме атмосферасы булдыру белән кызыксынган затларның иҗади потенциалын активлаштыру.

### Конкурсны үткәрү вакыты

Конкурс 2021 елның 15 декабреннән 2021 елның 25 декабренә кадәр үткәрелә.

## 2. Оештыру һәм катнашу шартлары

### 1. Конкурста катнашучылар

Конкурста районда яшәүче һәркем катнаша ала.

### 2. Номинацияләр

Конкурс җиңүчеләре «**Бина һәм аның янәшәсендәге территориянең иң яхшы Яңа ел бизәлеше**» номинациясе буенча билгеләнә.

### 3. Конкурс күрсәткечләре һәм бәяләү критерийлары

Конкурста катнашуга заявкаларны карау барышында түбәндәге критерийлар исәпкә алына:
- матурлыгы;
- оригинальлек;
- эшләрнең сыйфаты һәм техник башкарылышы;

- биналарны яктырту (төнге) һәм янәшәдәге территорияләрне бизәү өчен төрле материаллардан файдалану;
- кардан һәм боздан ясалган композицияләр булу;
- Яңа ел тематикасына туры килү;
- чыршы, биналарның сәнгати яктан, яктылык белән бизәлеше;
- янәшәдәге территорияләрне бизәү һәм чисталык;
- проектның инновацион характеры һәм идеяне тормышка ашыруга стандарт булмаган алымнар.

Конкурста берничә катнашучының баллар саны тигез булган очракта, җиңүче конкурс комиссиясенең барлык әгъзаларының ачык тавыш бирүен уздыру юлы белән билгеләнә. Конкурс комиссиясе карары утырышта катнашучыларның гади күпчелеге тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисе хәлиткеч тавыш хокукына ия.

Әгәр утырышта аның әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, конкурс комиссиясе үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы. Һәр пункт буенча бәяләү 5 баллы шкала буенча чыгарыла.

Җыелган баллар суммасы буенча җиңүчеләр билгеләнә. Конкурста максималь баллар җыйган катнашучы җиңүче дип таныла.

Конкурс комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

## 4. Бүләкләү

Конкурста йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү 2021 елның 30 декабрендә уздырыла.

Конкурс җиңүчеләрен бүләкләү тантаналы шартларда башкарыла.

Беренче 3 урынны алган җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата призлар, калганнар катнашучы дипломнары белән бүләкләнә.

Акчалата приз күләме:

1 урын - 5 000 сум
2 урын – 3 000 сум
3 урын – 1 000 сум

Кызыксындыру бүләге: 12* 500 сум=6 000 сум

**Барлыгы: 15 000 сум**

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгының ______________
_______ номерлы
күрсәтмәсе белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында биналарны һәм алар янәшәсендәге территорияләрне Яңа елга иң яхшы бизәүгә конкурсына нәтиҗәләр ясау буенча**
**КОНКУРС КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| **Рәисе:** | |
| Хәялиев Р.Р. | ТР Кайбыч муниципаль районы Башлыгы Урынбасары |
| **Комиссия әгъзалары:** | |
| 1. Макаров А.Н. | ТР Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе |
| 2. Айзатуллова Р.Г. | Совет Аппараты Җитәкчесе |
| 3. Бәдертдинова Д.А. | Башкарма комитет эшләре идарәчесе |
| 4. Заһидуллина Э.Х. | Башкарма комитет Җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары |
| 5. Петухова Ф.Ф. | Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| 6. Камалеева Р.Р. | Кайбыч районында ришвәтчелеккә каршы мәсьәләләр буенча Башлык ярдәмчесе |
| 7. Хәмидуллин И.И. | «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| 8. Петрова С.Т. | «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгының укыту-методик эшләр буенча мәгариф бүлеге урынбасары |
| 9. Әбләзова Р.Р. | Башкарма комитетның мәдәният бүлеге башлыгы |
| 10. Матвеева С.П. | Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башлыгы |
| 11. Сафина Л.Р. | Кошман авыл җирлеге башлыгы |
| 12.Сөнгатуллина Л.М. | «Кайбыч таңнары» («Кайбицкие зори») газетасы баш редакторы (килешү буенча) |